ГЛАВА СРЕДНЕКАМЫШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КАМЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Урта Камышлы ав.

КАРАР

«3» ноябрь 2021 ел

№ 2

Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 15 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Урта Камышлы авылы, Мәктәп урамы, 39нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылында Красноармейская урамындагы 1-57нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2021 елның 15 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Урта Камышлы авылы, Мәктәп урамы, 39нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылында Мәктәп урамы 1-73нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2021 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Урта Камышлы авылы, Мәктәп урамы, 39нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылында Совет урамы 1-54нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2021 елның 15 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Урта Камышлы авылы, Мәктәп урамы, 39нчы йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылында Садовая урамындагы 1-15, Мәктәп урамында 1-12 нче йортларда яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен Урта Камышлы авылында яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару.
- Урта Камышлы торак пунктында җирлек әһәмиятендәге юлларны ремонтлау.
- Зиратларның коймасын төзекләндерү һәм карап тоту
- Урам утларын көйләү

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы В.П. Вафина